**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАР №12**

**Урыссу ш.т.п. « 19 » 11 2020 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2014 елның 21 ноябрь "Җир салымы турында" №19 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 21.11.2014 ел, № 19 «Җир салымы турында» гы карарына (18.05.2015 ел, № 8, 09.10.2015 ел, № 19, 29.10.2018 ел, № 29, 16.12.2019 ел, № 22) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Салым ташламалары» 3 статьяның 2 пунктында:

1) 10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Торак төзелеше өчен, торак төзү өчен, индивидуаль торак төзелеше өчен, индивидуаль торак төзү өчен даими (сроксыз) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләе өлешендә оешмалар»;

2) 14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, үтү юллары, автомобиль юллары, скверлар, парклар, һәйкәлләр, су алу скважиналары, үләт базлары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары, торак пунктлар, спорт һәм гомуми файдаланудагы башка җирләр белән файдалану өчен даими (сроксыз) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешендә оешмалар".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр

тибындагы Урыссу поселогы территориясендәге махсус мәгълүмат стендларына куярга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 1 өлешендәге 5 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезендә 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башлыгы –**

**шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы Рәисе А. Ә.Шафигуллин**